


# *Мәктәбебез Гимны*

Зәңгәр күктә кояш елмайганда,
Чакырдың син белем иленә,
Һәм беренче сүздән, хәрефтән үк
Кереп калдың минем күңелемә.

Истә әле минем тәүге кабат
Бусагаңнан атлап керүем
Һәм тактада ак сызыклар белән
“Мәктәп”дигән сүзне күрүем.

Оныталмыйм шуны бүгенгәчә,
Мәңге калыр минем йөрәктә.
Истән чыкмас шушы бәхетле көн,
Нинди генә җирдә йөрсәк тә.

Онытмамын сине беркайчан да,
Изге йортым минем – мәктәбем.
Биргән белемең һәм тәрбияң өчен
Сиңа мең-мең рәхмәт әйтәмен.

***Р. Галимов сүзләре***
***Р. Курамшин көе***

# Мәктәп тарихы битләреннән




***Дөбъяз мәктәбенең беренче директоры Фазылҗан Хәмидуллин юбилей кичәсендә чыгыш ясый***

Дөбъяз авылында беренче совет мәктәбе 1918 нче елның октябрь аенда ачыла. Мәктәпне укытучы Фазылҗан Хәмидуллин оештыра. Мәктәпне оештыруда Ф.Хәмидуллинга авылның ярлылар комитеты рәисе Садыйк ага Сәгыев һәм авыл активисты Вәлиәхмәт Тимергалиев ярдәм итәләр.



***Дөбъяз мәктәбе укытучылары, алдынгы укучысы 1934 нче ел***

27 яшьлек Ф.Хәмидуллин Дөбъяз мәктәбенең оештыручысы да, беренче укытучысы да була. Авыл халкы беренче укытучыны җылы каршы ала һәм мәктәпне төзекләндерүдә, ягулык белән тәэмин итүдә кулларыннан килгән кадәр ярдәм итә. Фазылҗан ага Хәмидуллин Дөбъяз мәктәбендә 1922 нче елга кадәр эшли. Бу елны аны Казан өязе мәгариф инструкторы итеп чакыртып алалар. Соңга таба ул Казанда мәгариф министрлыгында мәктәпләр начальнигы, 1950 нче еллар башында ТИУУ директоры итеп билгеләнә.

Ф.Хәмидуллинны зур тәҗрибәле укытучы Сафин Тәүфыйк алыштыра. Алдынгы карашлы җитәкче буларак, ул мәктәпнең матди- техник базасын ныгытуга, мәктәп яны тәҗрибә участогын булдыруга зур өлеш кертә. 1926 нчы елда мәктәптә ВКП(б) өяз комитеты сәркатибе Гыйният Вәлиев тарафыннан беренче пионер оешмасы төзелә. Пионер дружинасына ТАССР оештырылуның 6 еллыгы хөрмәтенә татар халкының яраткан улы, революционер Мулланур Вахитов исеме бирелә. Бу уңайдан өяз комитеты сәркатибе Гыйният Вәлиев Казан шәһәреннән “Балалар шәһәрчеге” вәкилләрен Дөбъяз мәктәбенә кунакка чакыра. Менә шулай авыл белән шәһәр пионерлары арасында дуслык башланып китә.

1932нче елда алдынгы укытучы Хәйрулла Вәлиуллинны мәктәпнең директоры итеп куялар. Ул вакытта Дөбъяз мәктәбендә 750 укучы белем ала, 53 укытучы эшли. 1937 нче елда җидееллык Дөбъяз мәктәбе урта мәктәп итеп үзгәртелә.

Бөек Ватан сугышы укыту- тәрбия эшләрен башкача корырга мәҗбүр итә. 1941-1942 нче уку елында укыту планнарына һәм программаларына үзгәрешләр кертелә. Шул елны мәктәптәге барлык ир укытучылар сугышка алына. Ул еллардагы мәктәп директоры Фатыйма Габдрахман кызы Хәбибрахманова укытучылар коллективын уку-укыту һәм тәрбия эшләренә юнәлтү белән бергә, фронт өчен кирәк-яраклар җыйнау эшенә дә тарта.



***Мәктәпнең беренче төп бинасы***



***1962 нче елдан 1985 нче елга кадәр булган Дөбъяз мәктәбенең төп бинасы***



***Дөбъяз мәктәбенең бертөркем укытучылары. Уртада мәктәп директоры Фатыйма Хәбибрахманова***

# Мәктәп тарихы битләреннән



*1968 нче елда мәктәп укучылары субботникта*

Сугыш елларында да мәктәп, бернинди авырлыкларга да карамастан, укыту-тәрбия эшләрен тиешле югарылыкта алып бара.

1950-60 нчы елларда Дөбъяз урта мәктәбендә 500 гә якын бала белем алган, 40 ка якын укытучы балаларга белем биргән. Мәктәптә укучы балалар саны 60 нчы еллар азагында 440 ка калган. 1961 нче елда Дөбъязда район үзәге бетерелгәч, мәктәп элеккеге райбашкарма бинасына күчерелгән.



*Дөбъяз мәктәбенең 1968 нче елдагы укытучылары*

1965 нче елда мәктәп өчен өстәмә агач бина төзелә. Ул бинада башлангыч сыйныф укучылары белем ала, ә бер класс бүлмәсенә биология кабинеты урнаша.

Хисамиева Хәлимә Җәмәли кызы мәктәп җитәкчесе булып эшләгән чор бигрәк тә игътибарга лаек, чөнки нәкъ шул чорда эшчән, тату коллектив формалаша, мәктәпкә күпләп яшь укытучылар килә. Совет власте урнашуының 50 еллыгына багышлап 1966-1967 нче елларда мәктәптә туган якны өйрәнү музее ачыла.Бүгенге көндә дә бу музей мәктәбебезнең күрке булып тора.



*Дөбъяз мәктәбенең 1978 нче елдагы укытучылары*

1980 нче елларга кадәр мәктәптә ике сменага бүленеп укыйлар. Ул вакытта кечкенә мәктәптә 300 бала белем ала. Шул ук елларда мәктәбебезгә көчле һәм талантлы укытучылар килеп эшли башлый. Аларның күбесе шул вакыттан башлап мәктәптә 40 елдан артык хезмәт итәләр.

Укучыларга урын җитмәү сәбәпле Мәсхүт Гыйльфанов яңа бина төзүне башлап җибәрә. 1985 нче елны балалар яңа өч катлы мәктәп бинасына укырга күчәләр. Уку бүлмәләре иркен һәм уңайлы була, кирәкле уку әсбаплары белән тәэмин ителә, мәктәпнең материаль-техник базасы ныгый.

100 еллык юбилейны билгеләп үткән уку елында Дөбъяз урта гомуми белем бирү мәктәбендә 238 укучы белем ала. Бүгенге көндә мәктәпкә укырга Дөбъяздан тыш, тагын 5 авылдан 47 бала килә. Аларны 4 маршрут буенча ике автобус йөртә. 2017-2018 нче уку елларында мәктәптә 29 укытучы белем бирә.

Бүгенге көндә дә мәктәп тормышы гөрли. Талантлы укучылар, укытучылар ярдәме белән, белем алуда шәхси зур нәтиҗәләргә ирешәләр.



*3 нче сыйныф, 1978 нче ел*



*Чыгарылыш сыйныф укучылары, 1982 нче ел*



*1985 нче елда яңа мәктәп бинасын ачу тантанасы*



*Бүгенге мәктәп бинасы*

# Белем йортым минем-мәктәбем

## Алар - мәктәбебез горурлыгы



**Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаучылар:**

1. Петрянкина Светлана Андрей кызы 1965 ел
2. Галләмов Данил Хисмәт улы 1966 ел
3. Сабирова Миләүшә Рәхимҗан кызы 1966 ел
4. Гайнетдинова Гөлнар Гөмәр кызы 1966 ел
5. Усманов Айрат Марсел улы 1982 ел
6. Әхмәдиева Альбина Әлфрит кызы 1996 ел
7. Әхмирова Зәлинә Шамил кызы 1996 ел
8. Галләмов Айрат Азат улы 1997 ел
9. Галимов Ришат Илдүс улы 1998 ел
10. Низамова Ләйлә Солтан кызы 1998 ел
11. Фатыхова Алия Рөстәм кызы 1999 ел
12. Мөхетдинова Гөлия Фоат кызы 1999 ел
13. Сибгатуллина Лилия Илдар кызы 2002 ел
14. Сәйфетдинова Алсу Айдар кызы 2002 ел
15. Галләмов Марат Азат улы 2003 ел
16. Фатыйхова Гүзәл Рөстәм кызы 2003 ел
17. Булатова Лилия Әгъзәм кызы 2010 ел
18. Булатова Альбина Әгъзәм кызы 2011 ел
19. Галиуллина Гүзәл Рөстәм кызы 2012 ел
20. Нигъматуллина Миләүшә Самат кызы 2012 ел
21. Батрханова Айзилә Айдар кызы 2013 ел



**Мәктәпне көмеш медальгә тәмамлаучылар:**

1. Усманова Розалия Садрый кызы 1964 ел
2. Хәбибуллина Роза Абдулла кызы 1964 ел
3. Фатыйхова Фәридә Кашаф кызы 1965 ел
4. Шакирова Сания Хәбибрахман кызы 1965 ел
5. Әхмәдуллина Роза Гәбделрәшит кызы 1987 ел
6. Гайнетдинов Рөстәм Илдар улы 1987 ел
7. Гилязова Ризәлә Адел кызы 1987 ел
8. Садыйков Фәрит Әюп улы 1987 ел
9. Әхмәдуллина Рәмзия Гәбделрәшит кызы 1988 ел
10. Батрханова Лилия Илһам кызы 1989 ел
11. Зарипова Резеда Мәхмүт кызы 1989 ел
12. Низамов Руслан Солтан улы 1989 ел
13. Әскәрова Резеда Илшат кызы 1990 ел
14. Ибраһимова Гүзәл Йөзем кызы 1990ел
15. Хәйруллин Әнәс Камил улы 1990 ел
16. Әскәрова Флера Солтан кызы 1991 ел
17. Гыйниятуллина Гөлсинә Хафиз кызы 1991 ел
18. Кәримова Гөлфия Юрик кызы 1991 ел
19. Сиражиева Лилия Илдар кызы 1991ел
20. Галиева Әлфинур Мидхәт кызы 1991 ел
21. Гыйниятуллин Фәнис Хафиз улы 1992 ел
22. Гыйлфанова Фәридә Мәсхүт кызы 1992 ел
23. Лотфуллина Гөлнара Алберт кызы 1992 ел
24. Фәхретдинова Алсу Рәфыйк кызы 1992 ел
25. Әхмәдуллин Илдар Гәбделрәшит улы 1994 ел
26. Лотфуллина Гүзәлия Алберт кызы 1994 ел
27. Хәсәнова Резедә Ринат кызы 1994 ел
28. Кәримов Айрат Тәлгат улы 1995 ел
29. Шакирҗанова Ләйлә Госман кызы 1995 ел
30. Исхакова Резеда Гәбделсамат кызы 1996 ел
31. Корбанов Рөстәм Алберт улы 1998 ел
32. Бәширова Эльвира Ирекян кызы 2000ел
33. Гыйниятуллина Гөлназ Хафиз кызы 2000 ел
34. Петрянкин Александр Станислав улы 2000 ел
35. Сибгатуллин Илнар Илдар улы 2000 ел
36. Хәбибуллин Айрат Ренат улы 2000 ел
37. Спиридонов Алберт Гурий улы 2001 ел
38. Фәхретдинова Айсылу Рәфыйк кызы 2001 ел
39. Гайфуллина Алия Таһир кызы 2002 ел
40. Зарипова Фәридә Сөләйман кызы 2002 ел
41. Федотова Венера Николай кызы 2002 ел
42. Сайфетдинов Азат Айдар улы 2003 ел
43. Гарипова Светлана Равис кызы 2003 ел
44. Дамирян Марина Гегам кызы 2003 ел
45. Гөбайдуллина Резеда Радик кызы 2004 ел
46. Сабирҗанов Вадим Владимир улы 2004 ел
47. Федотова Лилия Николай кызы 2004 ел
48. Әхмәтҗанов Айнур Айдар улы 2005 ел
49. Хөсаинова Гөлназ Минәхмәт кызы 2005 ел
50. Вәлиуллина Әлинә Галимҗан кызы 2006 ел
51. Вәлеева Лилия Рәдиф кызы 2007ел
52. Сөнгатуллина Альбина Рәмис кызы 2007ел
53. Хөсәенова Гөлинә Рәшит кызы 2007ел
54. Булатова Энҗе Рәис кызы 2011ел
55. Мөхәмәтҗанова Рәлинә Ренат кызы 2011 ел
56. Шәрипова Айгөл Ренат кызы 2011 ел
57. Зарипова Диана Данис кызы 2013 ел
58. Ибатуллина Гөлүсә Рәшит кызы 2013 ел



**“За особые успехи в учении” медаленә лаек булган укучылар:**

1. Сатдинова Альмира Илгиз кызы 2014 ел
2. Галәүтдинова Алсу Ренат кызы 2014 ел
3. Булатова Регина Әгъзәм кызы 2015 ел
4. Саитова Әдилә Марат кызы 2016 ел
5. Фәхриева Ләйсән Марат кызы 2016 ел
6. Таҗиева Алия Фәрхәт кызы 2017 ел
7. Хөсәинов Инсаф Илнур улы 2018 ел
8. Әминова Ләйсән Алмаз кызы 2018 ел
9. Вафина Зилә Ренат кызы 2018 ел
10. Латыпова Илалия Ленар кызы 2018 ел
11. Корбанова Чулпан Хәмис кызы 2018 ел
12. Алмакаева Мария Шавкат кызы 2021 ел
13. Биккинеев Инсаф Рәдиф улы 2021 ел
14. Гибадуллина Рәмилә Фәрхәд кызы 2021 ел
15. Идрисова Гөлназ Илһам кызы 2021 ел
16. Исхакова Ләйсән Зөфәр кызы 2021 ел
17. Кәримова Регина Рамиль кызы 2022 ел
18. Хәйруллин Айназ Таһир улы 2022 ел